КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 23 июль

г.Казань

№ 544

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Иң яхшы муниципаль тәҗрибә» бөтенроссия конкурсының республика этабын уздыру турында» 2017 ел, 27 май, 313 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Иң яхшы муниципаль тәҗрибә» бөтенроссия конкурсының республика этабын уздыру турында» 2017 ел, 27 май, 313 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 24 апрель, 32 нче, 2018 ел, 20 июнь, 501 нче, 2020 ел, 21 февраль, 124 нче, 2020 ел, 10 апрель, 268 нче, 2020 ел, 25 июнь, 527 нче, 2021 ел, 21 июнь, 491 нче, 2022 ел, 15 июль, 682 нче, 2023 ел, 7 апрель, 428 нче, 2023 ел, 9 ноябрь, 1448 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган «Иң яхшы муниципаль тәҗрибә» бөтенроссия конкурсының республика этабын уздыру турында нигезләмәдә:

1.4 пунктның өченче һәм дүртенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль берәмлек территориясе белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыру»;

«Муниципаль берәмлекнең танылуын арттыру («территория бренды»);»;

1.5 пунктның өченче һәм дүртенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән берлектә «Муниципаль берәмлек территориясе белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыру» номинациясе буенча;

Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән берлектә «Муниципаль берәмлекнең танылуын арттыру («территория бренды»)» номинациясе буенча;»;

2.11 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.11. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән бергә, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты белән бергә, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән берлектә алар арасында конкурс номинацияләрен бүлү нигезендә ярдәмче комиссияләр төзиләр, алар:»;

3.3 пунктта:

беренче абзацта «25 июньнән 15 июльгә кадәр» сүзләрен «20 июньнән 10 июльгә кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

«б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына «Муниципаль берәмлек территориясе белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыру» һәм «Муниципаль берәмлекнең танылуын арттыру («территория бренды») номинацияләре буенча;»;

«в» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

3.5 пунктта «25 июльгә кадәр» сүзләрен «20 июльгә кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

3.7 пунктта «10 августка кадәр» сүзләрен «25 июльгә кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

3.10 пунктта «20 августка кадәр» сүзләрен «1 августка кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 3.11 пункт өстәргә:

«3.11. Конкурсның төбәк этабында җиңүче булмаган яисә анда катнашмаган, әмма аларның эшчәнлек практикасы Татарстан Республикасында иң яхшысы дип танылырга мөмкин булган муниципаль берәмлекләрнең конкурс заявкалары алга таба «Җирле үзидарәне үстерүнең бөтенроссия ассоциациясе» ассоциациясенә тапшыру өчен «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясенә җибәрелә. Бу очракта «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясенә конкурсның һәр номинациясе буенча конкурста катнашучыларның тиешле категориясендә муниципаль берәмлекләрнең кимендә биш конкурс заявкасын бирү срогы - 10 августтан да соңга калмыйча.»;

әлеге карар белән расланган «Иң яхшы муниципаль практика» бөтенроссия конкурсының республика этабын оештыру һәм уздыру буенча республика комиссиясе составында:

комиссия составыннан Р.Р.Гайзатуллинны, Л.Н.Шәфигуллинны, Ш.Ш.Яһудинны чыгарырга;

комиссия составына кертергә:

| | |
|---|---|
| Иванов Сергей Евгеньевичаны | Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисен |
| Фәйзрахманов Марат Җәүдәт улын | Татарстан Республикасы финанс министрын |

| | |
|---|---|
| Хөсәенов Рәгать Галиәхмәт улын | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты рәисен (килешү буенча) |
| Чубаров Александр Анатольевичны | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты рәисен (килешү буенча). |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин